**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИКЛӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

**КАРАР**

“09” ноябрь 2020 ел                    Биклән авылы                    №5

**“Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлегенең Биклән авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар жыенын билгеләү турында”**

“Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы “Биклән авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 13.1 ст. нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлегенең Биклән авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар жыенының беренче этабын 2020 елның 20 нче ноябре 14.00 сәгатькә билгеләргә.
2. Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлегенең Биклән авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар жыенының икенче этабын 2020 елның 21 нче ноябре 13.00 сәгатькә билгеләргә.
3. Гражданнар жыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Биклән авыл җирлегенең Биклән авылы территориясендә 2021 елда балигъ булган, Биклән авыл җирлегенең Биклән авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 300 (өч йөз) сум күләмендә билгеләргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләргә:

- Ахметшин урамында урнаштырылачак балалар мәйданчыгы өчен уен элементлары сатып алу ;
- Биклән авылы эчендәге юлларны, китереп бирү ысулы белән,вак таш (щебень) сатып алып,төзекләндерү;
- Чкалов һәм Мәгариф урамнарына жәяүлелр өчен тротуар төзү;
- Ахметшин һәм Чкалов урамнарын тоташтыручы жәяүлеләр басмасын яктылык челтәре сузып,жәяүлеләр өчен тротуар жәеп төзекләндерү;
- масса-күләм спорт белән шөгыльләнү өчен спорт инвентарьлары сатып алу;
- Биклән авылына керү юлын яктырту өчен яктылык челтәре төзү һәм кирәкле электр материаллары сатып алуга юнәлтергә.

**“ӘЙЕ”** **“ЮК”**

4. Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлегенең Биклән авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын Татарстан Республикасы Тукай районы Биклән авылы Чкалов урамы, 20А адресы буенча үткәрергә.
5. Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлегенең Биклән авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын Татарстан Республикасы Тукай районы Биклән авылы Ахметшина урамы, 69А адресы буенча үткәрергә.
6. Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
7. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.
8. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында “авыл җирлекләре” бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
7. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

Биклән авыл җирлеге Башлыгы М.Ш.Сәхбеев